| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| 423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38 | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38 |
| тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20 | тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 11 2022 г. №997

2022 елның IV кварталында
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы буенча
1 кв. м гомуми торак мәйданының
уртача базар бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасы, «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 865 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның IV кварталына Ютазы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының (сумнарда) уртача базар бәясен 30 571 (утыз мең биш йөз җитмеш бер) сум күләмендә расларга, күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары сатып алуга (төзүгә) бирелә торган гражданнар категорияләре өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Порталы составында «Рәсми Татарстан»

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча  урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-76-81